ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**26.06.2025** **Чистай шәһәре** **№ 287**

«Авиация эшләре, парашюттан сикерүләр, һава судноларының демонстрацион очышлары, пилотсыз очу аппаратлары очышлары, җирлек территориясе өстеннән бәйләнгән аэростатлар күтәрүгә рөхсәтләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 14 февралендәге 87 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 маендагы 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының "Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында" 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Авиация эшләре, парашюттан сикерүләр, һава судноларының демонстрацион очышлары, пилотсыз очу аппаратлары очышлары, җирлек территориясе өстеннән бәйләнгән аэростатлар күтәрүгә рөхсәтләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 14 февралендәге 87 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә.
1.1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Авиация эшләре, парашюттан сикерүләр, һава судноларының демонстрацион очышлары, пилотсыз очу аппаратлары очышлары, җирлек территориясе өстеннән бәйләнгән аэростатлар күтәрүгә рөхсәтләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 14 февралендәге 87 номерлы карары кушымтасында 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Төзелгән гарызнамәне формат-логик тикшерү орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче гарызнамәнең

электрон рәвешендәге һәр кырын тутырган вакытта, бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан электрон формадагы гарызнамә юлының дөрес тутырылмавы ачыкланса, мөрәҗәгать итүче ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерүнең тәртибе турында гарызнамәнең электрон формасының үзендә үк мәгълүмати хәбәр аркылы кисәтелә».

2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының ТКХ, төзелеш, транспорт, энергетика, элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов